ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12. 12. 2019 г. Заинск № 627

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында» 2018 елның 19 мартындагы 439 номерлы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Зәй муниципаль районында мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында» Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 мартындагы 439 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне чикләү турында нигезләмәсенә, 3.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3.17. Наркотик матдәләрне һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны иртә ачыклау максатларында укучылар арасында социаль-психологик тест оештыру. Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыру тәртибе гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.».

2. Зәй муниципаль районы башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Р. Печина
3 27 42